ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О профессиональных союзах»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
5 июня 2019 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 18 января 1995 года № 2303-XII «О профессиональных союзах» (Ведомости Верховного Совета Татарстана, 1995, № 1; Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2003, № 9 (II часть); 2011, № 4 (I часть); 2014, № 6 (II часть) изменения, изложив его в следующей редакции:

«ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О профессиональных союзах**

Глава 1. **Общие положения**

Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

1. Настоящий Закон регулирует общественные отношения, возникающие в связи с реализацией гражданами права на создание профессиональных союзов, права и гарантии деятельности профессиональных союзов, вопросы их взаимодействия с органами государственной власти Республики Татарстан, органами местного самоуправления, работодателями (их объединениями) в Республике Татарстан.

2. Правовое регулирование деятельности профессиональных союзов, объединяющих военнослужащих, сотрудников органов внутренних дел Российской Федерации, Государственной противопожарной службы Министерства Российской Федерации по делам гражданской обороны, чрезвычайным ситуациям и ликвидации последствий стихийных бедствий, органов федеральной службы безопасности, таможенных органов Российской Федерации, Следственного комитета Российской

Федерации, сотрудников войск национальной гвардии Российской Федерации, судей и прокуроров, определяется соответствующими федеральными законами.

Статья 2. **Правовая основа деятельности профессиональных союзов**

Правовую основу деятельности профессиональных союзов составляют Конституция Российской Федерации, Конституция Республики Татарстан, Федеральный закон от 12 января 1996 года № 10-ФЗ «О профессиональных союзах, их правах и гарантиях деятельности» (далее – Федеральный закон), настоящий Закон, а также иные нормативные правовые акты Российской Федерации и Республики Татарстан.

Статья 3. **Основные термины и понятия**

1. Профессиональный союз – добровольное общественное объединение граждан, связанных общими производственными, профессиональными интересами по роду их деятельности, создаваемое в целях представительства и защиты их социально-трудовых прав и интересов.
2. Иные термины и понятия, используемые в настоящем Законе, применяются в значениях, установленных Федеральным законом.

Статья 4. **Право граждан на создание профессиональных союзов**

1. Граждане, достигшие возраста 14 лет и осуществляющие трудовую (профессиональную) деятельность, имеют право свободно и добровольно, без предварительного разрешения, создавать профессиональные союзы для защиты своих интересов, вступать в них, заниматься профсоюзной деятельностью и выходить из профессиональных союзов. Гражданин может быть членом нескольких профессиональных союзов.
2. Профессиональные союзы могут создаваться гражданами в организациях независимо от форм собственности. Профессиональные союзы могут создаваться по профессиональному, отраслевому, профессионально-отраслевому, территориальному и иным признакам. Количество профессиональных союзов, создаваемых в рамках одной профессии (групп профессий), не ограничивается.
3. Принадлежность к профессиональным союзам и занятие профсоюзной деятельностью не влекут за собой ограничение социально-трудовых, политических и иных прав и свобод граждан, гарантируемых законодательством.
4. Все профессиональные союзы пользуются равными правами.

Статья 5. **Устав профессионального союза**

1. Профессиональные союзы, их объединения самостоятельно разрабатывают и утверждают свои уставы, свою структуру, образуют профсоюзные органы и определяют их компетенцию.
2. Требования, предъявляемые к уставам профессиональных союзов,

устанавливаются федеральным законодательством.

Статья 6. **Право профессиональных союзов на объединение**

1. Профессиональные союзы имеют право создавать свои объединения по отраслевому, территориальному или иному учитывающему профессиональную специфику признаку.

2. Профессиональные союзы вправе вступать в международные и другие профсоюзные объединения и организации, заключать с ними договоры и соглашения о сотрудничестве.

Статья 7. **Независимость профессиональных союзов**

1. Профессиональные союзы независимы в своей деятельности от органов исполнительной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, работодателей (их объединений), политических партий и других общественных объединений, им не подотчетны и не подконтрольны.

2. Запрещается вмешательство органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления и их должностных лиц, работодателей (их объединений) в деятельность профессиональных союзов, которое может повлечь за собой ограничение прав профессиональных союзов или воспрепятствование законному осуществлению их уставной деятельности.

3. Не допускается ограничение прав и гарантий деятельности профессиональных союзов, предусмотренных федеральными законами, законами Республики Татарстан, иными нормативными правовыми актами Российской Федерации и Республики Татарстан.

Статья 8. **Собственность профессиональных союзов**

В соответствии с Федеральным законом в собственности профессиональных союзов могут находиться земельные участки, здания, строения, сооружения, санаторно-курортные, туристические, спортивные, другие оздоровительные учреждения, культурно-просветительные, научные и образовательные организации, жилищный фонд, организации, в том числе издательства, типографии, а также ценные бумаги и иное имущество, необходимые для обеспечения уставной деятельности профессиональных союзов.

Статья 9. **Реорганизация, прекращение деятельности, приостановка, запрещение деятельности и ликвидация профессионального союза**

1. Порядок реорганизации, прекращения деятельности, ликвидации профессионального союза и использования его имущества в этих случаях определяется уставом профессионального союза в соответствии с федеральным законодательством.

2. Основания и порядок приостановления или запрещения деятельности профессиональных союзов устанавливаются федеральным законодательством.

## Глава 2. **Основные права профессиональных союзов**

### Статья 10. **Право профессиональных союзов на представительство и защиту социально-трудовых прав и интересов работников**

1. Профессиональные союзы, их объединения, первичные профсоюзные организации и их органы представляют и защищают права и интересы членов профессиональных союзов по вопросам индивидуальных трудовых и связанных с трудом отношений, а в области коллективных прав и интересов – указанные права и интересы работников независимо от членства в профессиональных союзах в случае наделения их полномочиями на представительство в установленном порядке.

2. Представители профессиональных союзов вправе беспрепятственно посещать организации и рабочие места, где работают члены соответствующих профессиональных союзов, для реализации уставных задач и предоставленных профессиональным союзам прав.

### Статья 11. **Право профессиональных союзов на содействие занятости**

Профессиональные союзы вправе принимать участие в разработке государственных программ Республики Татарстан в области занятости, предлагать меры по социальной защите членов профессиональных союзов, высвобождаемых в результате реорганизации или ликвидации организации, осуществлять профсоюзный контроль за занятостью и соблюдением законодательства в области занятости.

### Статья 12. **Право профессиональных союзов на ведение коллективных переговоров, заключение соглашений, коллективных договоров и контроль за их выполнением**

1. Профессиональные союзы, их объединения, первичные профсоюзные организации и их органы имеют право на ведение коллективных переговоров, заключение соглашений и коллективных договоров от имени работников в соответствии с федеральным законодательством.

2. Работодатели, их объединения, органы исполнительной власти Республики Татарстан и органы местного самоуправления обязаны вести коллективные переговоры с первичными профсоюзными организациями, профессиональными союзами, их объединениями по социально-трудовым вопросам, а также по вопросам заключения коллективных договоров, соглашений, если первичные профсоюзные организации, профессиональные союзы, их объединения выступают инициаторами таких переговоров, и заключать коллективные договоры, соглашения на согласованных сторонами условиях.

3. Первичные профсоюзные организации, профессиональные союзы, их объединения вправе осуществлять профсоюзный контроль за выполнением коллективных договоров, соглашений.

4. В случае нарушения работодателями, их объединениями, органами исполнительной власти Республики Татарстан и органами местного самоуправления условий коллективного договора, соглашения первичные профсоюзные организации, профессиональные союзы, объединения профессиональных союзов и их органы вправе направлять им представление об устранении этих нарушений, которое рассматривается в недельный срок. В случае отказа устранить эти нарушения или недостижения соглашения в указанный срок разногласия рассматриваются в соответствии с федеральным законом.

Статья 13. **Взаимодействие профессиональных союзов с работодателями, их объединениями, органами государственной власти Республики Татарстан и органами местного самоуправления по регулированию социально-трудовых прав и интересов граждан**

1. Взаимодействие профессиональных союзов с работодателями, органами государственной власти Республики Татарстан, органами местного самоуправления строится на основе социального партнерства.

2. Проекты нормативных правовых актов, затрагивающих социально-трудовые права работников, рассматриваются и принимаются органами государственной власти Республики Татарстан, органами местного самоуправления с учетом мнения территориальных организаций профессиональных союзов и их объединений.

3. Профессиональные союзы вправе выступать с предложениями о принятии органами государственной власти Республики Татарстан законов и иных нормативных правовых актов, касающихся социально-трудовой сферы. Профессиональные союзы вправе принимать участие в рассмотрении органами государственной власти Республики Татарстан, органами местного самоуправления, а также работодателями, их объединениями, другими общественными объединениями своих предложений.

4. Профессиональные союзы по согласованию с органами государственной власти Республики Татарстан, органами местного самоуправления вправе принимать участие в деятельности совещательных органов, созданных соответственно органами государственной власти Республики Татарстан, органами местного самоуправления для решения вопросов в сфере социально-трудовых отношений.

5. Взаимодействие профессиональных союзов с органами государственной власти Республики Татарстан и органами местного самоуправления может осуществляться путем заключения договоров и соглашений о взаимодействии и сотрудничестве в сфере социально-трудовых отношений, проведения совместных мероприятий, направленных на решение вопросов в указанной сфере, а также в иных формах, не запрещенных законодательством.

6. Профессиональные союзы вправе осуществлять взаимодействие с органами государственной власти Республики Татарстан, органами местного самоуправления, объединениями и организациями по развитию санаторно-курортного лечения, учреждений отдыха, туризма, массовой физической культуры и спорта.

Статья 14. **Право профессиональных союзов на участие в подготовке и дополнительном профессиональном образовании**

Профессиональные союзы вправе создавать образовательные организации и научные организации, осуществлять подготовку и дополнительное профессиональное образование профсоюзных работников и членов профессионального союза.

Статья 15. **Право профессиональных союзов на информацию**

1. Для осуществления своей уставной деятельности профессиональные союзы вправе бесплатно и беспрепятственно получать от работодателей, их объединений, органов государственной власти Республики Татарстан и органов местного самоуправления информацию по социально-трудовым вопросам.
2. Профессиональные союзы имеют право пользоваться государственными средствами массовой информации в порядке, определяемом договорами с их учредителями, освещать в них свою деятельность, а также могут быть учредителями средств массовой информации в соответствии с федеральным законодательством.

Статья 16. **Право профессиональных союзов на осуществление профсоюзного контроля за соблюдением законодательства о труде**

1. Профессиональные союзы имеют право на осуществление профсоюзного контроля за соблюдением работодателями, должностными лицами законодательства о труде, в том числе по вопросам трудового договора (контракта), рабочего времени и времени отдыха, оплаты труда, гарантий и компенсаций, льгот и преимуществ, а также по другим социально-трудовым вопросам в организациях, в которых работают члены данного профессионального союза, и имеют право требовать устранения выявленных нарушений. Работодатели, должностные лица обязаны в недельный срок с момента получения требования об устранении выявленных нарушений сообщить профессиональному союзу о результатах его рассмотрения и принятых мерах.
2. Для осуществления профсоюзного контроля за соблюдением законодательства о труде профессиональные союзы вправе создавать собственные инспекции труда, которые наделяются полномочиями, предусмотренными положениями, утверждаемыми профессиональными союзами.
3. Инспектора труда профессиональных союзов (профсоюзные инспектора труда) вправе беспрепятственно посещать организации независимо от форм

собственности и подчиненности, в которых работают члены данного профессионального союза, для проведения проверок соблюдения законодательства о труде и законодательства о профессиональных союзах, а также выполнения работодателями условий коллективного договора, соглашения.

Статья 17. **Права профессиональных союзов в области охраны труда и окружающей среды**

1. Профессиональные союзы вправе участвовать в формировании государственных программ Республики Татарстан по вопросам охраны труда и окружающей среды, а также в разработке нормативных правовых и других актов, регламентирующих вопросы охраны труда, профессиональных заболеваний и экологической безопасности.

2. Профессиональные союзы осуществляют профсоюзный контроль за состоянием охраны труда и окружающей среды через свои органы, уполномоченных (доверенных) лиц по охране труда, а также собственные инспекции по охране труда, действующие на основании положений, утверждаемых профессиональными союзами. В этих целях они имеют право беспрепятственно посещать организации независимо от форм собственности и подчиненности, их структурные подразделения, рабочие места, где работают члены данного профессионального союза, участвовать в расследовании несчастных случаев на производстве (работе), проведении специальной оценки условий труда на рабочих местах, защищать права и интересы членов профессионального союза по вопросам условий труда и безопасности на производстве (работе), возмещения вреда, причиненного их здоровью на производстве (работе), а также по другим вопросам охраны труда и окружающей среды в соответствии с федеральным законодательством.

3. В случаях выявления нарушений, угрожающих жизни и здоровью работников, профсоюзные органы в организации, профсоюзные инспектора по охране труда вправе потребовать от работодателя немедленного устранения этих нарушений и одновременно обратиться в территориальные органы федерального органа исполнительной власти, осуществляющего функции по контролю и надзору в сфере труда, занятости и альтернативной гражданской службы, для принятия неотложных мер.

4. При невыполнении требований по устранению нарушений, особенно в случаях появления непосредственной угрозы жизни и здоровью работников, профсоюзные органы, профсоюзные инспектора по охране труда вправе требовать от работодателя, органа управления организацией, должностного лица приостановления работ впредь до принятия окончательного решения территориальными органами федерального органа исполнительной власти, осуществляющего функции по контролю и надзору в сфере труда, занятости и альтернативной гражданской службы. Работодатель, должностное лицо за неустранение нарушений несут ответственность, предусмотренную законодательством.

5. Профессиональные союзы вправе участвовать в экспертизе безопасности условий труда на проектируемых, строящихся и эксплуатируемых производственных объектах, а также в экспертизе безопасности проектируемых и эксплуатируемых механизмов и инструментов.

Статья 18. **Права профессиональных союзов на социальную защиту работников**

Профессиональные союзы вправе принимать участие в формировании социальных программ, направленных на создание условий, обеспечивающих достойную жизнь и свободное развитие человека, разработке мер по социальной защите работников, в определении основных критериев жизненного уровня, размеров индексации заработной платы, пенсий, стипендий, пособий и компенсаций в зависимости от изменения индекса цен, а также вправе осуществлять профсоюзный контроль за соблюдением законодательства в указанной сфере.

Статья 19. **Право профессиональных союзов на защиту интересов работников в органах по рассмотрению трудовых споров**

1. В случаях нарушения законодательства о труде профессиональные союзы вправе по просьбе членов профессионального союза, других работников, а также по собственной инициативе обращаться с заявлениями в защиту их трудовых прав в органы, рассматривающие трудовые споры.

2. Для защиты социально-трудовых и других гражданских прав и профессиональных интересов своих членов профессиональные союзы могут создавать юридические службы и консультации.

Глава 3. **Гарантии прав профессиональных союзов**

Статья 20. **Оказание содействия профессиональным союзам**

Республика Татарстан оказывает содействие профессиональным союзам в реализации их уставных задач.

Статья 21. **Гарантии профсоюзным работникам**

1. Работники, освобожденные от работы вследствие избрания на выборные должности в профсоюзных органах, обладают такими же трудовыми правами, гарантиями и льготами, как и работники организации, индивидуального предпринимателя, в соответствии с коллективным договором.

2. Работникам, освобожденным от работы вследствие избрания на выборные должности в профсоюзных органах, после окончания их выборных полномочий предоставляется прежняя работа (должность), а также иная работа (должность) в случаях, предусмотренных Федеральным законом, Трудовым кодексом

Российской Федерации.

3. Расторжение трудового договора по инициативе работодателя с руководителями (их заместителями) выборных коллегиальных органов первичных профсоюзных организаций, выборных коллегиальных органов профсоюзных организаций структурных подразделений организаций (не ниже цеховых и приравненных к ним), не освобожденными от основной работы, а также расторжение трудового договора по инициативе работодателя с руководителем (его заместителями) выборного органа первичной профсоюзной организации в течение двух лет после окончания срока их полномочий допускается в порядке, предусмотренном Трудовым кодексом Российской Федерации.

4. Профсоюзным работникам предоставляются также иные права, гарантии и льготы, предусмотренные нормативными правовыми актами Российской Федерации и Республики Татарстан.

Статья 22. **Обязанности работодателей по созданию условий для деятельности профессиональных союзов**

В случаях и порядке, предусмотренных Федеральным законом, Трудовым кодексом Российской Федерации, работодатель предоставляет профессиональным союзам, действующим в организации, в бесплатное пользование необходимые для их деятельности оборудование, помещения, транспортные средства и средства связи, а также создает иные условия для деятельности соответствующего профессионального союза.

Статья 23. **Ответственность за воспрепятствование деятельности профессиональных союзов**

В случае нарушения положений настоящего Закона государственные органы, органы местного самоуправления, работодатели (их объединения) и иные должностные лица несут ответственность, предусмотренную законодательством.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
27 июня 2019 года
№ 54-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Һөнәр берлекләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 5 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Һөнәр берлекләре турында» 1995 елның 18 гыйнварындагы 2303-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1995, № 1; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 9 (II өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

**«Һөнәр берлекләре турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

1 бүлек. **Гомуми нигезләмәләр**

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон Татарстан Республикасында гражданнарның һөнәр берлекләре төзү хокукын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә барлыкка килә торган иҗтимагый мөнәсәбәтләрне, һөнәр берлекләре эшчәнлеге хокукларын һәм гарантияләрен, аларның Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, эш бирүчеләр (аларның берләшмәләре) белән үзара эшләү мәсьәләләрен җайга сала.

2. Хәрби хезмәткәрләрне, Россия Федерациясе Эчке эшләр органнары, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалардан килгән зыяннарны бетерү министрлыгының Янгынга каршы дәүләт хезмәте, федераль иминлек хезмәте органнары, Россия Федерациясе таможня органнары, Россия Федерациясе Тикшерү комитеты хезмәткәрләрен, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре хезмәткәрләрен, судьяларны һәм

прокурорларны берләштерә торган һөнәр берлекләре эшчәнлеген хокукый җайга салу тиешле федераль законнар белән билгеләнә.

2 статья. **Һөнәр берлекләре эшчәнлегенең хокукый нигезе**

Һөнәр берлекләре эшчәнлегенең хокукый нигезен Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Һөнәр берлекләре, аларның хокуклары һәм эшчәнлек гарантияләре турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 10-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – Федераль закон), әлеге Закон, шулай ук Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары тәшкил итә.

3 статья. **Төп терминнар һәм төшенчәләр**

1. Һөнәр берлеге – эшчәнлекләре төре буенча уртак производство, һөнәри мәнфәгатьләре булган гражданнарның вәкил булу һәм аларның социаль-хезмәт хокукларын, мәнфәгатьләрен яклау максатларында төзелә торган ирекле иҗтимагый берләшмәсе.
2. Әлеге Законда кулланыла торган башка терминнар һәм төшенчәләр Федераль законда билгеләнгән мәгънәләрдә кулланыла.

4 статья. **Гражданнарның һөнәр берлекләрен төзү хокукы**

1. 14 яшькә җиткән һәм хезмәт (һөнәри) эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гражданнар ирекле һәм ихтыярый рәвештә, алдан рөхсәт алмыйча, үз мәнфәгатьләрен яклау өчен һөнәр берлекләрен төзү, аларга керү, һөнәр берлеге эшчәнлеге белән шөгыльләнү һәм һөнәр берлекләреннән чыгу хокукына ия. Граждан берничә һөнәр берлегенең әгъзасы булып торырга мөмкин.
2. Һөнәр берлекләре гражданнар тарафыннан оешмаларда милек рәвешенә бәйсез рәвештә төзелә ала. Һөнәр берлекләре һөнәри, тармак, һөнәри-тармак, территориаль һәм башка билгеләр буенча төзелергә мөмкин. Бер һөнәр (һөнәр төркемнәре) кысаларында төзелә торган һөнәр берлекләренең саны чикләнми.
3. Һөнәр берлекләрендә тору һәм һөнәр берлеге эшчәнлеге белән шөгыльләнү гражданнарның законнар белән гарантияләнә торган социаль-хезмәт, сәяси һәм башка хокукларын һәм ирекләрен чикләүгә китерми.
4. Барлык һөнәр берлекләре дә тигез хокуклардан файдалана.

5 статья. **Һөнәр берлеге уставы**

1. Һөнәр берлекләре, аларның берләшмәләре мөстәкыйль рәвештә үзләренең уставларын, үз структурасын эшлиләр һәм раслыйлар, һөнәр берлегенең органнарын төзиләр һәм аларның компетенциясен билгелиләр.
2. Һөнәр берлекләре уставларына карата куела торган таләпләр федераль законнар белән билгеләнә.

6 статья. **Һөнәр берлекләренең берләшү хокукы**

1. Һөнәр берлекләре тармак, территориаль яисә һөнәри үзенчәлекне исәпкә ала торган башка билге буенча үз берләшмәләрен төзү хокукына ия.

2. Һөнәр берлекләре халыкара һәм башка һөнәр берлекләре берләшмәләренә, оешмаларына керергә, алар белән хезмәттәшлек итү турында шартнамәләр һәм килешүләр төзергә хокуклы.

7 статья. **Һөнәр берлекләренең бәйсезлеге**

1. Һөнәр берлекләре үз эшчәнлекләрендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, эш бирүчеләргә (аларның берләшмәләренә), сәяси партияләргә һәм башка иҗтимагый берләшмәләргә бәйле түгел, аларга хисап бирми һәм алар тарафыннан тикшерелми.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм аларның вазыйфаи затларының, эш бирүчеләрнең (аларның берләшмәләренең) һөнәр берлекләре эшчәнлегенә аларның хокукларын чикләүгә яисә устав эшчәнлекләрен законлы гамәлгә ашыруга комачаулык итүгә китерерлек катышуы тыела.

3. Һөнәр берлекләре эшчәнлегенең федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында каралган хокукларын һәм гарантияләрен чикләү рөхсәт ителми.

8 статья. **Һөнәр берлекләренең милке**

Федераль закон нигезендә һөнәр берлекләре милкендә һөнәр берлекләренең устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле җир кишәрлекләре, биналар, төзелмәләр, корылмалар, шифаханә-курорт, туристлык, спорт, башка сәламәтләндерү учреждениеләре, мәдәни-агарту оешмалары, фәнни оешмалар һәм мәгариф оешмалары, торак фонды, оешмалар, шул исәптән нәшриятлар, типографияләр, шулай ук кыйммәтле кәгазьләр һәм башка мөлкәт булырга мөмкин.

9 статья. **Һөнәр берлеге эшчәнлеген үзгәртеп кору, туктату, туктатып тору, эшчәнлекне тыю һәм һөнәр берлеген бетерү**

1. Һөнәр берлеге эшчәнлеген үзгәртеп кору, туктату һәм аны бетерү, мондый очракларда һөнәр берлеге мөлкәтеннән файдалану тәртибе федераль законнар нигезендә һөнәр берлеге уставы белән билгеләнә.

2. Һөнәр берлекләре эшчәнлеген туктатып тору яисә тыю нигезләре һәм тәртибе федераль законнар белән билгеләнә.

## 2 бүлек. **Һөнәр берлекләренең төп хокуклары**

### 10 статья. **Һөнәр берлекләренең вәкил булу һәм хезмәткәрләрнең социаль-хезмәт хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау хокукы**

1. Һөнәр берлекләре, аларның берләшмәләре, башлангыч һөнәр берлекләре оешмалары һәм аларның органнары һөнәр берлекләре әгъзаларының хокукларын һәм мәнфәгатьләрен индивидуаль хезмәт мәсьәләләре һәм хезмәткә бәйле мөнәсәбәтләр мәсьәләләре буенча, ә билгеләнгән тәртиптә вәкиллек вәкаләтләре бирелгән очракта, хезмәткәрләрнең һөнәр берлекләрендә әгъза булып торуларына карамастан, күмәк хокуклар һәм мәнфәгатьләр өлкәсендә аларның күрсәтелгән хокукларына һәм мәнфәгатьләренә вәкил була һәм аларны яклый.

2. Һөнәр берлекләре вәкилләре устав бурычларын һәм һөнәр берлекләренә бирелгән хокукларны гамәлгә ашыру өчен тиешле һөнәр берлекләре әгъзалары эшли торган оешмаларга һәм эш урыннарына тоткарлыксыз керү хокукына ия.

### 11 статья. **Һөнәр берлекләренең эш белән тәэмин итүгә булышу хокукы**

Һөнәр берлекләре эш белән тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләүдә катнашырга, оешманы үзгәртеп кору яисә бетерү нәтиҗәсендә эштән чыгарыла торган һөнәр берлекләре әгъзаларын социаль яклау чараларын тәкъдим итәргә, эш белән тәэмин ителешкә һәм эш белән тәэмин итү өлкәсендә законнар үтәлешенә һөнәр берлеге контролен гамәлгә ашырырга хокуклы.

### 12 статья. **Һөнәр берлекләренең күмәк сөйләшүләр алып бару, килешүләр, күмәк шартнамәләр төзү һәм аларның үтәлешен тикшереп тору хокукы**

1. Һөнәр берлекләре, аларның берләшмәләре, башлангыч һөнәр берлеге оешмалары һәм аларның органнары хезмәткәрләр исеменнән федераль законнар нигезендә күмәк сөйләшүләр алып бару, килешүләр һәм күмәк шартнамәләр төзү хокукына ия.

2. Эш бирүчеләр, аларның берләшмәләре, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары башлангыч һөнәр берлеге оешмалары, һөнәр берлекләре, аларның берләшмәләре белән социаль-хезмәт мәсьәләләре буенча, шулай ук, башлангыч һөнәр берлеге оешмалары, һөнәр берлекләре, аларның берләшмәләре күмәк сөйләшүләрнең инициаторлары булып торсалар, күмәк шартнамәләр, килешүләр төзү мәсьәләләре буенча күмәк сөйләшүләр алып барырга һәм яклар тарафыннан килештерелгән шартларда күмәк шартнамәләр, килешүләр төзергә тиеш.

3. Башлангыч һөнәр берлеге оешмалары, һөнәр берлекләре, аларның берләшмәләре күмәк шартнамәләр, килешүләр үтәлешенә һөнәр берлеге контролен гамәлгә ашырырга хокуклы.

4. Эш бирүчеләр, аларның берләшмәләре, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары күмәк шартнамә, килешү

шартларын бозган очракта, башлангыч һөнәр берлеге оешмалары, һөнәр берлекләре, һөнәр берлекләре берләшмәләре һәм аларның органнары аларга әлеге хокук бозуларны бетерү турында бер атна эчендә карала торган күрсәтмә җибәрергә хокуклы. Күрсәтелгән срокта әлеге хокук бозуларны бетерүдән баш тарткан яисә килешүгә ирешелмәгән очракта каршылыклар федераль закон нигезендә карала.

13 статья. **Һөнәр берлекләренең гражданнарның социаль-хезмәт хокукларын һәм мәнфәгатьләрен җайга салу буенча эш бирүчеләр, аларның берләшмәләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара эшләве**

1. Һөнәр берлекләренең эш бирүчеләр, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары белән үзара эшләве социаль партнерлык нигезендә төзелә.

2. Хезмәткәрләрнең социаль-хезмәт хокукларына кагылышлы норматив хокукый актлар проектлары, территориаль һөнәр берлекләре оешмалары һәм аларның берләшмәләре фикерен исәпкә алып, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан карала һәм кабул ителә.

3. Һөнәр берлекләре Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан социаль-хезмәт өлкәсенә кагылышлы законнар һәм башка норматив хокукый актлар кабул итү турында тәкъдимнәр белән чыгарга хокуклы. Һөнәр берлекләре Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук эш бирүчеләр, аларның берләшмәләре, башка иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан үз тәкъдимнәрен карауда катнашырга хокуклы.

4. Һөнәр берлекләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары белән килештереп, социаль-хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тиешенчә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан төзелгән киңәшмә органнар эшчәнлегендә катнашырга хокуклы.

5. Һөнәр берлекләренең Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара эшләве социаль-хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә үзара эшләү һәм хезмәттәшлек турында шартнамәләр һәм килешүләр төзү, әлеге өлкәдәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән уртак чаралар уздыру юлы белән, шулай ук законнар белән тыелмаган башка рәвешләрдә дә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

6. Һөнәр берлекләре Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, шифаханә-курорт дәвалавын үстерү берләшмәләре һәм оешмалары, ял, туризм, массакүләм физик культура һәм спорт учреждениеләре белән хезмәттәшлек итәргә хокуклы.

14 статья. **Һөнәр берлекләренең әзерләүдә һәм өстәмә һөнәри белем бирүдә катнашу хокукы**

Һөнәр берлекләре мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар булдырырга, һөнәр берлекләре хезмәткәрләрен һәм һөнәр берлеге әгъзаларын әзерләүне һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне гамәлгә ашырырга хокуклы.

15 статья. **Һөнәр берлекләренең мәгълүмат алу хокукы**

1. Һөнәр берлекләре үзләренең устав эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен эш бирүчеләрдән, аларның берләшмәләреннән, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан социаль-хезмәт мәсьәләләре буенча түләүсез һәм тоткарлыксыз мәгълүмат алырга хокуклы.
2. Һөнәр берлекләре дәүләт массакүләм мәгълүмат чараларыннан аларны гамәлгә куючылар белән шартнамәләрдә билгеләнгән тәртиптә файдаланырга, аларда үз эшчәнлекләрен яктыртырга хокуклы, шулай ук федераль законнар нигезендә массакүләм мәгълүмат чараларын гамәлгә куючылар булырга мөмкин.

16 статья. **Һөнәр берлекләренең хезмәт турындагы законнарның үтәлешенә һөнәр берлеге контролен гамәлгә ашыру хокукы**

1. Һөнәр берлекләре эш бирүчеләр, вазыйфаи затлар тарафыннан хезмәт турындагы законнарның үтәлешенә, шул исәптән хезмәт шартнамәсе (контракты), эш вакыты һәм ял вакыты, хезмәт өчен түләү, гарантияләр һәм компенсацияләр, ташламалар һәм өстенлекләр мәсьәләләре, шулай ук әлеге һөнәр берлеге әгъзалары эшли торган оешмалардагы башка социаль-хезмәт мәсьәләләре буенча һөнәр берлеге контролен гамәлгә ашыру хокукына һәм ачыкланган хокук бозуларны бетерүне таләп итү хокукына ия. Эш бирүчеләр, вазыйфаи затлар ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында таләп алынганнан соң бер атна эчендә һөнәр берлегенә аны карап тикшерү нәтиҗәләре һәм күрелгән чаралар турында хәбәр итәргә тиеш.
2. Хезмәт турындагы законнарның үтәлешенә һөнәр берлеге контролен гамәлгә ашыру өчен һөнәр берлекләре үз хезмәт инспекцияләрен төзергә хокуклы, аларга һөнәр берлекләре тарафыннан раслана торган нигезләмәләрдә каралган вәкаләтләр бирелә.
3. Һөнәр берлекләренең хезмәт инспекторлары (хезмәт буенча һөнәр берлеге инспекторлары) әлеге һөнәр берлеге әгъзалары эшли торган оешмаларга, аларның милек һәм буйсыну рәвешләре нинди булуга карамастан, хезмәт турындагы законнарның һәм һөнәр берлекләре турындагы законнарның үтәлешен, шулай ук эш бирүчеләрнең күмәк шартнамә, килешү шартларының үтәлешенә тикшерүләр үткәрү өчен тоткарлыксыз керергә хокуклы.

17 статья. **Хезмәтне һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә һөнәр берлекләренең хокуклары**

1. Һөнәр берлекләре хезмәтне һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт программаларын төзүдә, шулай ук хезмәтне

саклау, һөнәри авырулар һәм экологик хәвефсезлек мәсьәләләрен регламентлаштыра торган норматив хокукый һәм башка актларны эшләүдә катнашырга хокуклы.

2. Һөнәр берлекләре хезмәтне һәм әйләнә-тирә мохитне саклау торышына һөнәр берлеге контролен үз органнары, хезмәтне саклау буенча вәкаләтле (ышанычлы) затлар аша, шулай ук һөнәр берлекләре тарафыннан раслана торган нигезләмәләргә таянып эшли торган хезмәтне саклау буенча үз инспекцияләре аша гамәлгә ашыралар. Бу максатларда алар, милек һәм буйсыну рәвешләре нинди булуга карамастан, оешмаларга, аларның структур бүлекчәләренә, әлеге һөнәр берлеге әгъзалары эшли торган эш урыннарына тоткарлыксыз керергә, производствода (эштә) бәхетсезлек очракларын тикшерүдә, эш урыннарында хезмәт шартларын махсус бәяләүдә катнашырга, производствода (эштә) хезмәт шартлары һәм куркынычсызлык, производствода (эштә) сәламәтлегенә килгән зыянны каплау мәсьәләләре, шулай ук федераль законнар нигезендә хезмәт һәм әйләнә-тирә мохитне саклауның башка мәсьәләләре буенча һөнәр берлекләре әгъзаларының хокукларын һәм мәнфәгатьләрен якларга хокуклы.

3. Хезмәткәрләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч яный торган хокук бозуларның булуы ачыкланган очракларда оешмадагы һөнәр берлеге органнары, хезмәтне саклау буенча һөнәр берлеге инспекторлары эш бирүчедән әлеге хокук бозуларны кичекмәстән бетерүне таләп итәргә һәм кичектергесез чаралар күрү өчен хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм альтернатив граждан хезмәте өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыра торган федераль башкарма хакимият органының территориаль органнарына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

4. Хокук бозуларны бетерү буенча таләпләр үтәлмәгән очракта, бигрәк тә хезмәткәрләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә турыдан-туры зыян килү куркынычы барлыкка килгән очракларда, һөнәр берлеге органнары, хезмәтне саклау буенча һөнәр берлекләре инспекторлары эш бирүчедән, оешма белән идарә итү органыннан, вазыйфаи заттан хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм альтернатив гражданлык хезмәте өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыра торган федераль башкарма хакимият органының территориаль органнары тарафыннан хәлиткеч карар кабул ителгәнчегә кадәр эшне туктатып торуны таләп итәргә хокуклы. Эш бирүче, вазыйфаи зат хокук бозуларны бетермәгән өчен законнарда каралган җаваплылыкка ия була.

5. Һөнәр берлекләре проектлана, төзелә һәм эксплуатацияләнә торган производство объектларында хезмәт шартларының куркынычсызлыгына экспертизада, шулай ук проектлана һәм эксплуатацияләнә торган механизмнар һәм эш кораллары куркынычсызлыгына экспертизада катнашырга хокуклы.

### 18 статья. **Һөнәр берлекләренең хезмәткәрләрнең социаль яклануына хокуклары**

Һөнәр берлекләре кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итә торган шартлар булдыруга юнәлдерелгән социаль программаларны төзүдә, хезмәткәрләрне социаль яклау чараларын эшләүдә, тормыш дәрәҗәсенең төп критерийларын, хезмәт хакын, пенсияләрне, стипендияләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне бәяләр

индексы үзгәрүдән чыгып индексацияләү күләмнәрен билгеләүдә катнашырга хокуклы, шулай ук күрсәтелгән өлкәдә законнар үтәлешенә һөнәр берлеге контролен гамәлгә ашырырга хокуклы.

19 статья. **Һөнәр берлекләренең хезмәт бәхәсләрен карау органнарындагы хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклау хокукы**

1. Хезмәт турындагы законнар бозылган очракларда һөнәр берлекләре һөнәр берлеге әгъзаларының, башка хезмәткәрләрнең үтенече буенча, шулай ук үз инициативасы белән хезмәт бәхәсләрен карый торган органнарга, хезмәт хокукларын яклау турындагы гаризалар белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2. Һөнәр берлекләре үз әгъзаларының социаль-хезмәт һәм башка гражданлык хокукларын һәм һөнәри мәнфәгатьләрен яклау өчен юридик хезмәтләр һәм консультацияләр оештыра ала.

3 бүлек. **Һөнәр берлекләре хокукларына гарантияләр**

20 статья. **Һөнәр берлекләренә ярдәм күрсәтү**

Татарстан Республикасы һөнәр берлекләренә аларның устав бурычларын тормышка ашыруда ярдәм күрсәтә.

21 статья. **Һөнәр берлекләре хезмәткәрләренә гарантияләр**

1. Һөнәр берлеге органнарының сайланулы вазыйфасына сайлануга бәйле рәвештә эштән азат ителгән хезмәткәрләр күмәк шартнамә нигезендә, оешма, индивидуаль эшкуар хезмәткәрләре кебек үк, хезмәт хокукларына, гарантияләргә һәм ташламаларга ия була.

2. Һөнәр берлеге органнарының сайланулы вазыйфасына сайлануга бәйле рәвештә эштән азат ителгән хезмәткәрләргә, аларның сайланулы вәкаләтләре тәмамлаганнан соң, элеккеге эш (вазыйфа), шулай ук Федераль законда, Россия Федерациясе Хезмәт кодексында каралган очракларда башка эш (вазыйфа) бирелә.

3. Эш бирүче инициативасы буенча башлангыч һөнәр берлеге оешмаларының сайланулы коллегиаль органнарының, оешмаларның структур бүлекчәләре (цехтан һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән дә түбәнрәк түгел) һөнәр берлеге оешмаларының сайланулы коллегиаль органнарының төп эшләреннән азат ителмәгән җитәкчеләре (аларның урынбасарлары) белән хезмәт шартнамәсен эш бирүче инициативасы буенча өзү, шулай ук башлангыч һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы җитәкчесе (аның урынбасарлары) белән хезмәт шартнамәсен аларның вәкаләтләре срогы тәмамланганнан соң ике ел эчендә эш бирүче инициативасы буенча өзү Россия Федерациясе Хезмәт кодексында каралган тәртиптә рөхсәт ителә.

4. Һөнәр берлеге хезмәткәрләренә шулай ук Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган башка хокуклар, гарантияләр һәм ташламалар бирелә.

22 статья. **Һөнәр берлекләре эшчәнлеге өчен шартлар тудыру буенча эш бирүчеләрнең бурычлары**

Федераль законда, Россия Федерациясе Хезмәт кодексында каралган очракларда һәм тәртиптә эш бирүче оешмада эшли торган һөнәр берлекләренә аларның эшчәнлеге өчен кирәкле җиһазлар, биналар, транспорт чаралары һәм элемтә чараларын түләүсез файдалануга бирә, шулай ук тиешле һөнәр берлегенең эшчәнлеге өчен башка шартлар тудыра.

23 статья. **Һөнәр берлекләре эшчәнлегенә каршылык күрсәткән өчен җаваплылык**

Әлеге Закон нигезләмәләре бозылган очракта дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, эш бирүчеләр (аларның берләшмәләре) һәм башка вазыйфаи затлар законнарда каралган җаваплылыкка ия була.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 27 июнь
№ 54-ТРЗ